РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

13 февраль 2015ел                                                                                   № 7-45

**«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 98 статьясы нигезендә Буа муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Буа район Советының 2011 елның 16 сентябрендәге 5-13 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 10.1 статьяны кертергә:

**«10.1статья Сатып алулар өлкәсендә аудит**

Контроль-хисап палатасы Буа муниципаль районы ихтыяҗлары өчен сатып алулар өлкәсендә аудит һәм «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 98 статьясында билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

2. «Буа муниципаль районының контроль-хисап палатасы» МКУ рәисе А.Р.Вәлиулинга муниципаль хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары И.Ф.Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе                    А.К. Айзетуллов